**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская,
дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы.,
38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

№ 34 «01» февраля 2019г.

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районында
“Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары)
программасын гамәлгә ашыру максатыннан
балаларны белем бирү оешмаларына
исәпкә кую һәм күчерү турында
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр кертү”

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 нче елның 10 нчы мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган һәм 2018 нче елның 26 нчы декабрендә чыккан 1975/18 номерлы “Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) программасын гамәлгә ашыру максатыннан балаларны белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм күчерү турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү” боерыгы нигезендә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының 2015 нче елының 25 нче маенда расланган 219 нчы номерлы карары нигезендә “Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) программасын гамәлгә ашыру максатыннан балаларны белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм күчерү турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү” (Әтнә районы Башкарма комитетының 2015 нче елның 26 нчы октябрендәге 347 нче номерлы, 2016 нчы елның 2 нче июнендәге 206 нчы номерлы, 2017 нче елның 28 нче июлендәге 276 нчы номерлы карарлар

белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) турындагы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 нче пунктның:

3.4.4 нче бүлегенә түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

“Өстенлекнең вакыты чыгу белән гариза бирүчегә оешмага чиратсыз һәм беренче чиратта җибәрелү хокукын раслатырга кирәк”;

3.4.6 нчы бүлекнең өченче кызыл юлын түбәндәгечә бәян итәргә:

“Административ регламентның 3нче пунктында каралган тәртип нигезендә, уку елы дәвамында буш урыннар булу белән оешмаларда өстәмә комплектлаштыру үткәрелә”;

3.4.5 нче бүлекнең алтынчы кызыл юлында “биш эш көненнән дә артык түгел” дигән сүзләрне “бер эш көненнән дә артык булмаган эш көне” сүзләренә алмаштырырга;

3.5.3 нче бүлекнең өченче кызыл юлында “3 ай эчендә” сүзләрен “бер ай эчендә” сүзләренә алмаштырырга»;

3.5.4 нче бүлекнең беренче кызыл юлына түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә:

“Гариза бирүче оешмага җибәрелгән юлламадан баш тарткан очракта, кабул итү вакыты мөрәҗәгать иткән көннән дә алда куелмый”;

3.5.5 нче бүлекнең беренче кызыл юлында “Оешма җитәкчесе гаризага “килмәде” статусын билгели” дигән җөмләне, “Гаризага “килмәде” статусы бирелә” дигән сүзләр белән алмаштырырга»;

3.5.6 нчы пунктның беренче кызыл юлын түбәндәгечә тулыландырырга:

“Муниципаль хезмәт алуга ихтыяҗны раслау вакыты мөрәҗәгать иткән көннән дә алдарак башкарылмый”;

3.6.3 нче пунктның беренче кызыл юлын түбәндәгечә тулыландырырга:

“Муниципаль хезмәт алуга ихтыяҗны раслау вакыты мөрәҗәгать иткән көннән дә алдарак башкарылмый”;

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” җитәкчесенә йөкләргә.

Әтнә районы башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы: А. Ф. Каюмов